**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карары**

Мәлбагыш авылы №110 11октябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советы 2017 елның 13 ноябрендәге 71 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибенең 1.7 пунктының үз көчен югалткан дип тану турында

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасы нигезендә

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советы 2017 елның 13 ноябрендәге 71 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен арендага бирү тәртибе турында» (җир кишәрлекләреннән тыш), муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче зат хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен» карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибенең 1.7 пунктының үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.Ә.Әхтәмова